РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 28 » 12 2024 ел №1243

2025 елга социаль наем шартнамәләре
һәм муниципаль торак фондының торак
урыннарына наем шартнамәләре буенча
торак урыннарны яллаучылар өчен торак
урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү)
күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Төзелеш Министрлыгының 06.04.2018 ел, № 213/пр "Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау турында, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында» боерыгы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. 2025 елга социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләмен кушымта нигезендә 2025 елның 1 гыйнварыннан билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә торак хезмәтләре күрсәткән өчен түләү күләмен раслау турында»гы 13.12.2023 ел, №2096 карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru; Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән 17.12.2013 ел, №ФС77-60244 ЭЛ массакүләм мәгълүмат

чарасы буларак теркәлү турында таныклык) буенча бастырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүматтелекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Габдрахманова Г.Г.
2-42-06

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына кушымта
_____________ 2024 ел № _______

**2025 елга социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме**

| Түләү исеме | Үлчәү берәмлеге | 01.01.2025 түләү күләме | 01.07.2025 елдан түләү күләме |
|---|---|---|---|
| Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урынны наемга алган өчен түләү | сум./кв.м. | 8,11 | 8,69 |